ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.06.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1461**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 маендагы 300 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 мартындагы 825 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «2022 елның 1 гыйнварыннан» дигән датаны «2024 елның 1 июленнән» дигән дата белән алыштырырга;

күрсәтелгән карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының « «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 декабрендәге 3127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 мартындагы 825 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 04 июнендәге
1461 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 19 242 |
| 2 | 1,0126 | 19 484 |
| 3 | 1,0256 | 19 735 |
| 4 | 1,0381 | 19 975 |
| 5 | 1,0521 | 20 245 |
| 6 | 1,0656 | 20 504 |
| 7 | 1,0802 | 20 785 |
| 8 | 1,0942 | 21 055 |
| 9 | 1,1083 | 21 326 |
| 10 | 1,1233 | 21 615 |
| 11 | 1,1379 | 21 895 |
| 12 | 1,1535 | 22 196 |
| 13 | 1,1691 | 22 496 |
| 14 | 1,1846 | 22 794 |
| 15 | 1,2008 | 23 106 |
| 16 | 1,2174 | 23 425 |
| 17 | 1,2340 | 23 745 |
| 18 | 1,2512 | 24 076 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладны) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә